**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «23» августыннан № 228

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 июнендәге 243 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 ноябрендәге 542 номерлы, 2020 елның 11 июнендәге 146 номерлы, 2021 елның 21 октябрендәге 263 номерлы, 2021 елның 19 ноябрендәге 454 номерлы, 2022 елның 28 мартындагы 93 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 06 сентябрендәге 821 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 июнендәге 243 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VI бүлекнең 14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.3. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указы белән билгеләнгән, гомуми белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү учреждениесенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үтәлә торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен гомуми белем бирү учреждениесенең җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына кызыксындыру характерындагы түләүләр, локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең стимуллаштыру характерындагы түләүләренең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

әлеге карар белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

V бүлекнең 13.3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме мәктәпкәчә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үтәлә торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен гомуми белем бирү учреждениесенең җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына кызыксындыру характерындагы түләүләр, локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим

һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләрнең чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат– телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов